**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2017 ел, 3 апрель | № 206

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар теленең электрон сүзлеге» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2013 ел, 26 март, 201 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар теленең электрон сүзлеге» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2013 ел, 26 март, 201 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктның өченче абзацында «һәм муниципаль берәмлекләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган «Татар теленең электрон сүзлеге» дәүләт мәгълүмат системасы турында нигезләмәдә:

1.3 нче пунктта:

өченче абзацта «һәм муниципаль берәмлеге» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының административ-территориаль берәмлекләре исемнәре сүзлеге операторы – Татарстан Республикасының административ-территориаль берәмлекләре исемнәре сүзлеген мәгълүмати тәэмин итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы;»;

алтынчы абзацта «, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.5 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

2.1 нче пунктта:

бишенче абзацны үз көчен югалткан дип санарга;

алтынчы абзацта «операторларга» сүзен «гомуми операторга» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 нче пунктта:

беренче абзацта «һәм муниципаль берәмлекләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Электрон сүзлектәге мәгълүматны актуальләштерү (кертү, аңа төзәтмәләр кертү) өчен, Татарстан Республикасында административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрына үзгәрешләр кертү турындагы норматив хокукый акт басылып чыкканнан соң 10 эш көне эчендә гомуми операторга Татарстан Республикасының административ-территориаль берәмлекләре составы һәм/яки исемнәре үзгәрү хакындагы мәгълүматны электрон рәвештә җибәрә;»;

2.3 нче пунктның икенче абзацында «сүзлек берәмлеген тәрҗемә итү өчен электрон сорау кергәннән соң өч эш көне эчендә» сүзләрен «кирәк булган саен, әмма кимендә ярты елга бер тапкыр» сүзләренә алмаштырырга;

2.4 нче пунктта:

беренче абзацта «һәм Татарстан Республикасы административ-территориаль берәмлекләре һәм муниципаль берәмлекләре исемнәре сүзлеге операторының» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «һәм Татарстан Республикасының административ-территориаль берәмлекләре һәм муниципаль берәмлекләре исемнәре сүзлеге операторы» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «сорау җибәргән оператор» сүзләрен «гомуми оператор» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 нче пунктта «һәм Татарстан Республикасының административ-территориаль берәмлекләре һәм муниципаль берәмлекләре исемнәре сүзлеге операторы» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.1 нче пунктта:

икенче абзацта «, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\206.doc